Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Бакырчы авыл җирлегенең Бакырчы торак пунктында 2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында гражданнар җыены карары

13 .11. 2024 № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бакырчы авыл җирлегенең Бакырчы торак пунктында гражданнар җыены карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бакырчы авыл җирлегенең Бакырчы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге уку формасындагы студентлардан, балачактан инвалидлардан тыш, 2025 елда гражданнарның үзара салымын 1000 ( бер мең) сум күләмендә кертергә. махсус хәрби операциядә катнашучылар (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, ирекләләр) һәм аларның гаилә әгъзалары, атап әйткәндә: ата-аналар, ир белән хатын, балигъ булган балалар.

2. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Газизҗан урамындагы 1 нче йорттан алып Такташ урамындагы 1 нче йортка кадәр Бакырчы торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (вак таш, ком сатып алу, нигезне әзерләү, ташу, салу, эш өчен түләү)?

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Бакырчы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (https://tetushi.tatarstan.ru/) һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы» нда (https://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

Җитәкче И.М.Шәмсетдинов